**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 17 августындагы 2881 номерлы карары**

# «Новая волна 2026» халыкара конкурсына әзерлек һәм аны уздыру чорында Казан шәһәре автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында

«Новая волна 2026» халыкара конкурсын уздыру чорында иминлекне тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яки вакытлыча туктату тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. 2026 елның 19 августында 00.00 сәгатьтән 2026 елның 26 августында 23.59 сәгатькә кадәр, кирәк булган очракта, түбәндәге участокларда транспорт чараларын куюны һәм хәрәкәтен чикләүне кертергә:

1.1.1. Чистай урамы буйлап, А.Бичурин урамыннан Ямашев проспектына кадәр, А.Бичурин урамыннан хәрәкәт иткәндә (С.Хәким урамы юнәлешендә Ф.Әмирхан урамына чыгу юлыннан кала);

1.1.2. С.Хәким урамы буйлап, Ф.Әмирхан урамыннан Чистай урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә дә);

1.1.3. Ямашев проспекты буйлап, Адоратский урамыннан Себер Тракты урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә дә);

1.1.4. Академик Арбузов урамы буйлап, Журналистлар урамыннан Ямашев проспектына кадәр, Журналистлар урамыннан хәрәкәт иткәндә;

1.1.5. Чистай урамы буйлап, Ямашев проспектыннан Адоратский урамына кадәрге участокта, Ямашев проспектыннан хәрәкәт иткәндә;

1.1.6. Гаврилов урамының дублеры буйлап, Маршал Чуйков урамыннан Чистай урамына кадәрге участокта;

1.1.7. «Ак Барс Арена» стадионы тирәли әйләнеп үзу юлы буйлап;

1.2. юл хәрәкәтен оештыру техник чараларын һәм таранга каршы техника урнаштыру өчен җаваплы итеп конкурсны оештыручыны билгеләргә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.3.1. транспорт хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында юл билгеләрен урнаштыру һәм каплау буенча оештыручыга ярдәм күрсәтергә;

1.3.2. транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм MTC.URENT) һәм велосипед («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю буенча эшне оештырырга;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе (Р.Х.Шәмсетдинов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе (Р.Р.Фәтхетдинов) белән берлектә хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорына таранга каршы техника куюда оештыручыга ярдәм күрсәтергә;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән

участокларында транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**